КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 12 май г.Казань № 327

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 2 июнь, 331 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 40 нчы; 2020 ел, 22 апрель, 316 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган юридик затларга аларны оештыру (шул исәптән үзгәртеп оештыру юлы белән) турындагы язуларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына керткән датадан 14 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен исәпкә алу буенча автоматлаштырылган мәгълүмат системасы белән хезмәттәшлек итү өчен махсуслаштырылган программа продуктын (алга таба – махсуслаштырылган программа продукты) урнаштыруны гамәлгә ашырырга.»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Юридик затларга мөлкәт белән эш итү турындагы карар кабул ителгән датадан 14 көн эчендә Нигезләмәнең 2.3 пункты нигезендә формалаштырылган мәгълүматларны Реестрга Татарстан Республикасы мөлкәте составы турындагы мәгълүматларны кертү, үзгәртү яки төшереп калдыру өчен нигез булып торган документлар белән бергә кертергә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктка «, шулай ук андагы мәгълүматны бирү тәртибе» сүзләрен өстәргә;

1.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Реестрның исәпкә алу объекты (алга таба – исәпкә алу объекты) булып Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт (җир кишәрлекләрен кертеп), шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт казнасыныкы булган мөлкәт (җир кишәрлекләрен кертеп), тиешле шартнамәләр нигезендә юридик һәм физик затларга файдалануга бирелгән мөлкәт (җир кишәрлекләрен кертеп), шулай ук хокук ияләренә башка әйбер хокукында караган мөлкәт (җир кишәрлекләрен кертеп) тора:»;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«кадастр кыйммәте, мең сум.»;

2 пунктта:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалануга тапшыру датасы;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«файдалы файдалану срогы;

Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгының 2014 елның 12 декабрендәге 2018-ст номерлы боерыгы белән кабул ителгән Төп фондларның гомумроссия классификаторындагы 013-2014 нче гомумроссия классификаторы нигезендә төп фондлар төренә (кодны күрсәтеп) кертү;

3 пунктта:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалануга тапшыру датасы;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«файдалы файдалану срогы;

Төп фондларның гомумроссия классификаторы нигезендә төп фондлар төренә (кодны күрсәтеп) кертү.»;

4 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалануга тапшыру датасы;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«файдалы файдалану срогы;

Төп фондларның гомумроссия классификаторы нигезендә төп фондлар төренә (кодны күрсәтеп) кертү.»;

6 пунктта:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалануга тапшыру датасы;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«файдалы файдалану срогы;

Төп фондларның гомумроссия классификаторы нигезендә төп фондлар төренә (кодны күрсәтеп) кертү.»;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«файдалануга тапшыру датасы;

файдалы файдалану срогы;

Төп фондларның гомумроссия классификаторы нигезендә төп фондлар төренә (кодны күрсәтеп) кертү.»;

8 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалануга тапшыру датасы;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«файдалы файдалану срогы;

Төп фондларның гомумроссия классификаторы нигезендә төп фондлар төренә (кодны күрсәтеп) кертү.»;

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Төп фондларның гомумроссия классификаторы нигезендә төп фондлар төренә (кодны күрсәтеп) кертү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин